**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Сарлинского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Центральная, д.68А, с. Сарлы,
423315
Тел. 365-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Үзәк урам, 68А,
Сарлы авылы, 423315
Тел. 365-34

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» июль, 2018 ел №12

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең 2018 елның 02 апрелендәге 4 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен закупкалар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар әзерләү һәм кабул итү тәртибенә таләпләрне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләргә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы, «Заказ бирүчеләрнең сатып алына торган аерым төр товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә) таләпләрне билгеләү буенча гомуми кагыйдәләрне раслау турында» 2015 елның 2 сентябрендәге карарлары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең 2018 елның 02 апрелендәге 4 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен закупкалар өлкәсендә нормалаштыру турында

хокукый актлар әзерләү һәм кабул итү тәртибенә таләпләрне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләргә үзгәреш кертергә, 17 пунктындагы «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«б) җирлек башкарма комитетының үзе, казна учреждениеләре, бюджет учреждениеләре һәм унитар предприятиеләр тарафыннан сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләрен) сайлап алу тәртибе (алга таба - ведомство исемлеге);».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык М.Р.Шәрипов